Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш), № 79 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктында «муниципаль торак контролен,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 17 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктында «муниципаль торак контролен,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

2026 елның 1 сентябреннән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Бердәм гавами хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлешенең 29 пунктындагы «д» пунктчасының үз көчен югалтуын тану хакында» 2026 елның 20 февралендәге 23-ФЗ номерлы Федераль законның нигезләмәләре үз көченә керә, аның нигезендә муниципаль торак контроле юкка чыгарыла (бу өлкәдә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре региональ дәрәҗәгә тапшырыла).

Шуңа бәйле рәвештә закон проектында әлеге өлкәдә шәһәр округларының һәм шәһәр җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре исемлегеннән төшереп калдыру тәкъдим ителә. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына шундый ук үзгәрешләр кертелә).

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү түбәндәгеләргә үзгәрешләр кертүне таләп итә:

- «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә конкуренцияне үстерү чаралары турында» 2010 елның 9 апрелендәге 251 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;
- «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;
- «Торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турында карар кабул ителә торган территория чикләрендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан блоклы төзелгән йортлар һәм индивидуаль торак төзелеше объектлары тузуның югары дәрәҗәсен, аларның техник торышының тиешле дәрәҗәдә булмавын, мондый йортларда һәм объектларда инженер-техник тәэмин итү системаларының булмавын характерлый торган критерийларны раслау хакында» 2025 елның 28 ноябрендәге 1014 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанслау таләп итми.